ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№24 Кече Урыссу ав. «26» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Ташкичү авыл җирлоеге” муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 ноябрендәге 12 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Вәкаләтле орган карарларына, вәкаләтле орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү» турындагы 6 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Вәкаләтле орган карарларына, муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

6.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдә тотылучы затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль чаралар үткәрү турында карарлар;

2) контроль чаралар актлары, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр;

3) Муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның

контроль чаралар кысаларында гамәлләре (гамәл кылмавы).

6.3. Шикаять тикшереп торылучы зат тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып, шикаятьне карарга вәкаләтле органга электрон рәвештә бирелә.

Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне һәм документларны үз эченә алган шикаять, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланмыйча, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган бүтән сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып бирелә. Тиешле шикаятьне контрольдә тотылучы зат Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кабул итүендә, шикаятьтә (документларда) дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка сер булып торучы белешмәләрнең булуы турында алдан хәбәр итеп, бирә.

6.4. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала.

6.5. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдә тотылучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яисә белергә тиеш булган көннән алып 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Вәкаләтле органның күрсәтмәсенә шикаять контрольдә тотылучы зат күрсәтмә алган вакыттан алып 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогы нигезле сәбәпләр аркасында үткәрелгән очракта, шикаять бирүче затның үтенече буенча бу срок вәкаләтле орган тарафыннан кире кайтарылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул иткәнче аны тулысынча яисә өлешчә кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

6.6. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять вәкаләтле орган теркәлгән көннән алып 20 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Әгәр аны карау өчен башка органнар карамагында булган белешмәләрне алу таләп ителсә, шикаятьне карау срогы Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан 20 эш көненнән дә артыгракка озайтылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендәге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы челтәр басмасында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2014 елның 17 декабрендәге ЭЛ ФС77-60244 санлы ММЧны теркәү турындагы таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре

порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» интернет челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев